**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Глава
Балтачевского сельского
поселения» Азнакаевского
муниципального района**

ул. Молодежная, д 1а , с. Балтачево
Азнакаевского муниципального района
423302, Тел. (8-292) 4-47-23

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы
«Балтач авылы жирлеге
Советы башлыгы**

Азнакай муниципаль районы, Балтач авылы,
Яшьлэр урамы, 1а
423302, Тел. (8-292) 4-47-23

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» сентябрь 2022 ел № 3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Балтач торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең Балтач торак пунктында, Балтач авылында теркәлгән һәм А.Алиш урамы буенча 1- 25, Яшьлэр урамы 1- 70 йортлар буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын 2022 елның 01октябрендә 09 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең Балтач торак пунктында, Балтач авылында теркәлгән һәм Узэк урамы буенча 1 -42,8 Март урамы 1 -37 нче йортлар буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын 2022 елның 01октябрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3.Билгеләү:
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Балтач авыл җирлегендә үзара салым кертү буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башкарма комитеты.;
- гражданнар Җыенының беренче этабын уздыру вакыты-2022 елның 01 октябрендә 09.00 сәгатьтән 10.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар Җыенының икенче этабын уздыру вакыты-2022 елның 01 окябрендә 11.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр;

4.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2022 елның 25 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга Балтач авылы, Молодежная урамы, 1А йорт адресы буенча бирергә.;
"Татар теле" фәнен өйрәнүгә карата уңай омтылышта булу, татар теле белән даими кызыксыну һәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштерү.;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;
- Балтач торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.
5.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез, 2023 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар,80 яшьтән өлкәнерәк пенсионерлар өчен 200 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Балтач торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:
- Балтач авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү;
- Балтач авылы территориясендә чүп үләннәрен чабу;
- Трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- Трактор өчен җиһазлар сатып алу;
- Балтач авылы зираты территориясендә чүп үләннәрен чабу, чүп-чар җыю;
- Балтач авылы юлларын төзекләндерү;
- Янгынга каршы эшчәнлек, янгын инвентаре сатып алу

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru бүген Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http//aznakayevo.tatarstan.ru) һәм Балтач авылы,Молодежная ур., 1А йорт,Центральная ур., 37 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында.
7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Рәис Л.Л.Хәбипов